ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЫ

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ

## БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫКЛАРЫН ФОРМАЛАШТЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ
И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

2021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ
ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»
ӨСТӘМӘ ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ
МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫКЛАРЫН ФОРМАЛАШТЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

## Методик тәкъдимнәр

Казан
2021

ББК 74.202.4
Т 12

*ТРМҮИ гыйльми советы карары нигезендә басыла*
*Гомуми редакция: Ногманова Л.Н., ТР Мәгарифне үстерү институты ректоры, педагогика фәннәре докторы;*
*Яковенко Т.В., ТР Мәгарифне үстерү институтының фәнни һәи инновацион эшчәнлек буенча проректоры, педагогика фәннәре кандидаты*

**Автор-төзүче:**
**Җамалетдинова Зәлфирә Исхак кызы,** ТРМҮИ мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирү кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты
**Рецензентлар: Фәттахова Рузилә Фирдавис кызы,** ТРМҮИ татар теле һәм татар әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; **Бичурина Сеимбикә Усман кызы,** Федераль дәүләт автоном мәгариф югары уку йорты «Казан (Идел) федераль университеты» доценты, педагогика фәннәре кандидаты.

Татар теле һәм әдәби уку дәресләрендә башлангыч сыйныф укучыларының функциональ грамоталылыкларын формалаштыру үзенчәлекләре: методик тәкъдимнәр / авт.-т.: Җамалетдинова З.И. — Казан: ТРМҮИ, 2021. — 48.

Методик тәкъдимнәрдә функциональ грамоталылык төшенчәсе ачыла, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә функциональ грамоталылыкны формалаштыру, дәрес-конспектларда, гомумән, педагогик эшчәнлектә функциональ грамоталылыкны формалаштыру юлларын чагылдыру ысуллары бирелә. Башлангыч мәктәптә эшләүче татар теле укытучыларына тәкъдим ителә.

© ТРМҮИ, 2021

Укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерү мәгариф системасында бүген актуаль проблема. Педагогик хезмәткәрләр, җитәкчеләр, белем бирү оешмалары алдында укучыларның белем сыйфатын күтәрү, укытучының һөнәри осталыгын үстерү, укучыларны халыкара тикшерүләргә әзерләү бурычы куелды.

Иң элек һәркемгә таныш булган «Укытучының һөнәри үсеше» дигән милли система нигезендә укучыларның белем дәрәҗәсен күрсәтүче фактор мәктәп укытучысының һөнәри сыйфатлары һәм осталыгы тора диелгән. Шуннан чыгып, соңгы вакытта укытучының һөнәри осталыгына, эшчәнлек нәтиҗәләренә закон нигезендә, хокукый документлар буенча таләпләр «Мәгариф» проектында, 2025нче елга кадәр «Мәгарифне үстерү» дәүләт программасында билгеләнде.

2018 нче елның 7нче маенда чыккан "2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары» һәм 2030 елга кадәр Россия үсешенең милли максатлары турындагы Указлар нигезендә (2020 елның 21 июлендәге) 2021 нче елга гомуми белем бирү буенча Россия беренче унлыкка керергә тиеш диелгән.

Бу уңышлар халыкара тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыклана.

Белгәнегезчә, төрле үсешнең нигезе башлангыч сыйныфларда салына, шул сәбәпле, башлангыч сыйныф укытучысы көнүзәк проблемаларның барысы буенча да хәбәрдар булырга тиеш.

Халыкара тикшерүләрдә катнашуның әһәмияте нидән гыйбарәт?

Беренчедән, халыкара эзләнүләр, тикшеренүләр башка илләр белән чагыштырып карау мөмкинлеге бирә.

Икенчедән, тикшерүләр халыкара дәрәҗәдә булгач, яңа мониторинг уздыру технологияләре кулланыла. Алга таба ул технологияләрне Россия башка тикшерүләрне оештырганда куллана ала.

Тикшерү материаллары анализы аша функциональ грамоталылыкны тәшкил итүче һәр компонентның эчтәлеге, катнашучылары, күрсәткечләре үзләштерелә, алар укучыларны

халыкара тикшерүләргә әзерләү өчен этәргеч, юнәлеш, критерийлар булып тора.

2019 елның августыннан 6 юнәлеш буенча да (математика, табигать фәннәре, финанс, уку грамоталылыгы, глобаль компетенцияләр һәм креатив фикерләү сәләте) 5 нче һәм 7 нче сыйныф укучыларының функциональ грамоталылыгын бәяләү өчен күрсәтмә материаллар ачылды. Материаллар барлык компонентлар буенча функциональ грамоталылыкны бәяләүнең төп алымнарын, диагностика эшләрнең демонстрацион вариантларын, биремнәргә характеристикаларны һәм бәяләү системасын үз эченә ала. Материаллар педагогик кадрларның квалификациясен күтәрү системасында куллану өчен тәкъдим ителә.

Диагностик эшләр ФДБФУ «Россия мәгариф академиясенең мәгарифне үстерү стратегиясе институты» порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырылган http://skiv.instrao.ru/

Иң элек без мәгариф мохитен булдырырга тиешбез. Гади генә әйткәндә, гомуми белем бирү оешмаларының төп бурычы – укучылар яңа белем – күнекмәләргә ия булсын һәм көндәлек тормышта алган белемнәрдән, эффектив технологияләрдән нәтиҗәле файдалана алсын өчен барлык мөмкинлекләр һәм шартлар тудыру.

Эшне нидән башларга кирәк соң?

Хәзерге заман укытучысының һөнәри үсешендә аның технологик компетентлылыгын формалаштыру проблемасы иң мөһиме булып тора. Ул үз эченә теоретик яктан тирән әзерлекне һәм дәресләрдә заманча белем бирү технологияләрен нәтиҗәле куллануның практик тәҗрибәсен, укучыларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, аларны адаптацияләүгә һәм модификацияләүгә әзерлекне ала.

Бу юнәлештә гомуми белем бирү оешмалары белән максатчан эшчәнлек алып бару уңышлы була. Квалификация күтәрү, укыту семинарлары, вебинарлар, кыска вакытлы чараларны даими оештыру һәм иң мөһиме һәр белем бирү оешмасында өйрәтү характерындагы гамәли юнәлештәге чаралар оештыру.

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы «юл картасы»на ОФЛАЙН һәм ОНЛАЙН режимда да ел дәвамында гамәли һәм инструктив чаралар кертелгән һәм алар план нигезендә алып барыла. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы яңалыкларын күзәтү, башка гомуми белем бирү оешмалары белән хезмәттәшлек аша хәбардар булу зарур.

Һичшиксез, башта функциональ грамоталылыкны формалаштыруның теоретик-методологик нигезләрен өйрәнергә кирәк. Кирәкле хокукый документларны игътибар белән төгәл үзләштереп эшне оештыру отышлы була.

Беренчедән, без функциональ грамоталылыкның нәрсә икәнен төгәл күзалларга тиеш. Функциональ грамоталылык төшенчәсен ачканчы, без функциональ грамоталылык һәм метапредмет нәтиҗәләр арасындагы аермалы үзенчәлекләрне билгелибез.

Функциональ грамоталылык һәм метапредмет нәтиҗәләр һәрвакыт янәшә бара. Әмма метапредмет нәтиҗәләргә уку-укыту чаралары аша, кейсларга операция ясамыйча гына да ирешеп була, ягъни барысы да фән эчендә башкарыла, йомгаклау аттестациясенә чыгарыла.

Укучы үзендә белем алу процессында алган күнекмәләрне теләсә нинди предмет материалы белән эшләгәндә иркен кулланысын өчен без гомуми алымнарга, техникаларга, схемаларга, фикерләү эшчәнлеге үрнәкләренә өйрәтергә тиешбез. Ул күнекмәләрне формалаштыру мөһим, чөнки метапредмет нәтиҗәләре югары предмет нәтиҗәләренә ирешү мөмкинлеге тудыра.

Ә функциональ грамоталылыкны формалаштырганда без кейсларга, предметара бәйләнешләргә чыкмыйча булдыра алмыйбыз.

Россия Президентының 2018 нче елгы 5нче маендагы указыннан күренгәнчә, укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштырып, без максатчан рәвештә белем бирү сыйфатын күтәрү, уку сыйфатын күтәрү өстендә эшлибез.

Галимнәр функциональ грамоталылыкның ике компонентын билгелиләр.

Беренчесе предмет компонентларын үз эченә ала, төп белем бирү программасының уку курсларын үзләштергәндә укучының казанышларын чагылдыруны күздә тота. Предмет компонентлары башлангыч мәктәптә өйрәнелә торган уку предметларына туры килә.

Предметның компетентлылыгы – әйләнә-тирә чынбарлыкта барлыкка килгән проблемаларны, уку мәсьәләләрен предмет чаралары, белемнәренә таянып чишүне хәл итү, предмет чаралары белән танышу, аларны әлеге фән телендә формалаштыру, мотивлаштыру һәм интерпретацияләү мөмкинлеге.

Интегратив компонент киңрәк, уку, мәгълүмати, коммуникатив һәм социаль грамоталылыкны үз эченә ала.

Ике компонент бер-берсенә тыгыз бәйле, бер-берсенә җәйле рәвештә үстерелә, формалаша.

Ике компонент та барлык халыкара тикшерү материалларына керә.

Функциональ грамоталылыкның статусы югары, чөнки функциональ грамоталылык астында гади биремнәр юк, алар барысы да тормыш ситуациясенә уралып бара.

Шәхси нәтиҗәләр белем алуның тирән мәгънәсен төшенү, әхлакый-этик юнәлеш бирү, предмет белемнәренең һәм күнекмәләренең социаль яктан кирәклеген аңлау буенча җаваплылыкны арттыра, мотивацияне уята.

Метапредмет нәтиҗәләре (универсаль уку гамәлләре + предметара төшенчәләр) предмет эчтәлеге белән креатив эшләү мөмкинлеге бирә.

Проект эшчәнлеге социаль эшчәнлекнең мөһимлеген тормышка ашыру өчен шартлар тудыра.

Предмет нәтиҗәләре әйләнә-тирә дөнья күренешләре турында күзаллаулар бирә, функциональ грамоталылыкның белем-мәгълүмат каркасын формалаштыра. Фән нәтиҗәләре генератор булып кала, алар калган фәннәрне үзләштерү өчен көчле нигез булып тора.

Функциональ грамоталылыкның төп өлеше буларак математик, уку, табигый-фәнни, финанс грамоталылыгы, глобаль компетенцияләр һәм креатив фикерләү аерылып күрсәтелгән. 2015 елга кадәр өч компонентны (математик, табигый-фәнни,

уку грамоталылыгы) тикшерделәр, 2015 елда финанс грамоталылыгын, 2018 нче елда глобаль компетенцияләрне һәм 2021 нче елда креатив фикерләү халыкара PISA тикшерүләренә өстәделәр.

**PIRLS, TIMSS, PISA, TALIS** халыкара тикшерүләре уздырыла.

Кыскача, аларның эчтәлекләрен карап китик.

**PIRLS** тикшерүендә укучыларның укуы һәм текстны аңлавы тикшерелә. Тикшерү 5 елга бер тапкыр уздырыла. 10, 5 - 11 яшькә кадәр башлангыч сыйныфны тәмамлаучы укучылар тикшерелә.

**TIMSS** башлангыч һәм урта сыйныфларда математика һәм табигать фәннәре буенча белемнәрне тикшерүне күздә тота. Бу тикшерүнең максаты башлангыч һәм урта звеноның сыйфат күрсәткечен чагыштыру, чөнки математик һәм табигый-фәнни грамоталылык алга таба белем алуның нигезе булып тора. Тикшерү 4 елга бер тапкыр уздырыла. Тикшерүләр нәтиҗәсендә өч проблема ачыкланды:

1) Өй эшенең күләме зур булуы.
2) урта звенода белем сыйфатының кискен төшүе.
3) укытучыларның үз эшләреннән канәгать булмавы.

Проблемаларны ачыклау алга таба аларны төзәтү буенча эш алып барырга юнәлеш бирә.

**PISA** тикшерүендә 15 яшьтәге яшүсмерләрнең өч елга бер тапкыр математика, табигый-фәнни һәм уку грамоталылыгын тикшерәләр. 2015 нче елда беренче тапкыр финанс грамоталылыгын тикшерделәр. Бу юнәлештә нәтиҗәләр буенча Россия беренче 20 лекккә дә кергәне юк. Иң кызганычы 2015 нче елда күрсәткечләр яхшырак иде. Ә соңгы тикшерүләрнең нәтиҗәсе күпкә түбән. Бу бу юнәлештә эшнең системалы оештырылмавын күрсәтә.

## Россия Федерациясенен PISA тикшерүләрендәге нәтиҗәләр

| | РФ башка катнашучы илләр арасындагы урыны (баллар саны буенча) | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Тикшерү юнәлешләре** | **PISA-2000** | **PISA-2003** | **PISA-2006** | **PISA-2009** | **PISA-2012** | **PISA-2015** | **PISA-2018** |
| Табигый-фәнни грамоталылык | 26 | 24 | 35 | 39 | 37 | 32 | 33 |
| Математика грамоталылыгы | 22 | 29 | 34 | 38 | 34 | 23 | 30 |
| Уку грамоталы-лыгы | 27 | 32 | 39 | 43 | 42 | 26 | 31 |

| **Тикшерү юнәлешләре** | **РФ башка катнашучы илләр арасындагы урыны *** | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Табигый-фәнни грамоталылык | **PISA-2000** | **PISA-2003** | **PISA-2006** | **PISA-2009** | **PISA-2012** | **PISA-2015** | **PISA-2018** |
| Математика грамоталылыгы | 26-29 | 20-30 | 33-38 | 38-40 | 34-38 | 30-34 | 30-37 |
| Уку грамоталы-лыгы | 21-25 | 29-31 | 32-36 | 38-39 | 31-39 | 20-30 | 27-35 |
| | 27-29 | 32-34 | 37-40 | 41-43 | 38-42 | 19-30 | 26-36 |

** Халыкара хисапта стандарт тайпылышларны исәпкә алып, илнең урыны күрсәтелә*

| | **РФ нең баллар саны (1000-баллы шкала буенча)** | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Тикшерү юнәлешләре** | **PISA-2000** | **PISA-2003** | **PISA-2006** | **PISA-2009** | **PISA-2012** | **PISA-2015** | **PISA-2018** |
| Табигый-фәнни грамоталылык | 460 | 489 | 479 | 478 | 486 | 487 | 478 |
| Математика грамоталылыгы | 478 | 468 | 476 | 468 | 482 | 494 | 488 |
| Уку грамоталы-лыгы | 462 | 442 | 440 | 459 | 475 | 495 | 479 |

**TALIS** тикшерүендә инде укучыларны түгел, ә укытучыларны һәм директорларны тикшерәләр. Тикшерү 5 елга бер тапкыр уздырыла. 2008, 2013 һәм 2018 нче еллардауздырылды.

Тикшерүләр буенча түбәндәге нәтиҗәләр ясалды:

1) Россия укытучыларының яшь үзенчәлеге башка илләрдән өлкәнрәк икәне ачыкланды.

2) Россия укытучылары бер предметтан артык укытмый, эш урынын еш алыштырмый.

3) Россия укытучылары чит ил укытучыларыннан күбрәк эшли, административ эшкә күп вакытын сарыф итә.

4) Россия укытучыларының авыр гаиләдәге, предметларны авыр үзләштерүче балаларга игътибары җитми.

Барлык тикшерүләрдән соң белем бирү процессын оештыру буенча махсус тәкъдимнәр эшләнә. Мәгариф өлкәсендә булган барлык киңәшмәләрдә дә белем сыйфаты югары булсын өчен функциональ грамоталы шәхес тәрбияләү мәсьәләсе күтәрелде.

Нинди була соң ул функциональ грамоталы шәхес?

Функциональ грамоталы шәхес — гомере буе алган белем, күнекмәне тормышта төрле өлкәләрдә килеп чыккан проблемаларны, мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлеген киң кулланып, социаль мөнәсәсбәтләр урнаштыра һәм аралаша алучы.

Функциональ шәхес тышкы дөнья белән аралашырга әзер, ул үзенең ныклы белеменә таянып, мәктәптән тыш мөнәсәбәтләр кора, иркен итеп шул даирәдә үз эшчәнлеген алып бара, тормышта килеп чыккан ситуациядән чыгып эш итә белергә өйрәнә. Гади итеп әйтсәк, укучыны әйләнә-тирә үзе тәрбияли, үзе каршылыгын куя, төрле юллар тәкъдим итә, укытучы булган белемнәрен кулланып, кирәкле юлга чыга. Ә укучыга белем кирәклекне төшендерү иң авыры. Шуңа күрә укытучы иң элек теоретик белемнәрне үзләштерә, аннан аны гамәлдә уңышлы куллану ысулларын өйрәнә, сынап карый. Теоретик белем уңышның нигезе булып тора.

Шуңа күрә иң элек функциональ грамоталылыкның компонентларын, эчтәлегенә тукталыйк.

Грамоталы уку — үзмаксатка ирешү, белем һәм мөмкинлекләрне үстерү, җәмгыять тормышында актив катнашу өчен язма текстларны кабул итү, аңлау һәм аларның эчтәлеген куллану сәләте.

Математик грамоталылык — кешеләрнең дөньяда математиканың ролен билгели алу һәм аңлау, нигезләнгән математик фикер йөртүләр, иҗади, кызыксынучан һәм фикерле шәхес буларак, үз ихтыяҗыңны бүген һәм киләчәктә канәгатьләндерер өчен математиканы куллану.

Табигый-фәнни грамоталылык — әйләнә-тирәне, кешелек эшчәнлеге тарафыннан барлыкка килгән үзгәрешләрне кабул итү һәм аңлау өчен фәнни методлар белән тикшерелә һәм чишелә торган тормыштагы реаль проблемаларны аерып алу сәләте.

Уку грамоталылыгы — язма текстларны аңлау һәм аңлау, аларның эчтәлеген үз максатларына ирешү, белем һәм мөмкинлекләр үстерү, җәмгыять тормышында актив катнашу сәләте. Уку грамоталылыгы-функциональ грамоталылыкның төп компоненты.

Ә грамоталы уку база грамоталылыгы булып тора, чөнки ул башка компонентларның да яртысын диярлек тәшкил итә.

Барлык төр компонент эчендә грамоталы уку математик һәм табигый-фәнни гармоталылыкның 33 %ын, ә глобаль компетенцияләрнең 22 % тәшкил итә. Ә барлык компонентларның үзара бәйләнешен тәэмин итү өчен дә 4 % грамоталы уку дәрәҗәсе кирәк.

Бу күнекмәләр элек гомумуку күнекмәсендә чагылыш таба иде, алга Федераль дәүләт белем стандартларында метапредмет нәтиҗәләре буларак гамәлгә керде (Универсаль уку гамәлләре, предметара төшенчәләр: ИКТ-компетентлылык. Уку. Текст белән эш. Мәгълүмат белән эшләү күнекмәсе).

Глобаль компетенцияләр ИКТ-компетентлылыкны үз эченә ала. Федераль дәүләт белем стандартында мәгълүмати белем бирү даирәсе эчтәлеге аерып күрсәтелгән, белем бирү оешмаларыныда мәгълүмати белем даирәсенең нинди булырга тиешлеге, нәрсәләрне үз эченә алганы язылган.

ИКТ-компетентлылык метапредмет нәтиҗәләренең бер өлеше булып торганын беләбез.

Коммуникатив грамоталыллык шулай ук метапредмет нәтиҗәлрен тәшкил итә. Сөйләм культурасы, тел чараларын куллана белү коммуникатив грамоталылыкның нигезе.

Социаль грамоталылык нигезендә укучының үзе кылган гамәлләре өчен җавап бирә белүе тора.

Моның өчен укучы бик тәрбияле итеп (цивилизованно) төрле проблемаларны, конфликтларны уртак кулай фикергә

килеп хәл итә, дәлилли һәм башкалар кабул итәрлек дәрәҗәдә аңлата белергә тиеш була.

Предмет һәм интегратив компонентлар тыгыз бәйләнгән дидек, шул сәбәпле интегратив компонентлар предмет компонентларыннан башка үсә һәм формалаша алмый.

Барлык компонентларның формалашуына да нигез булып, әлбәттә, функциональ грамоталылыкның предмет компонентлары тора, чөнки нәрсә турында булса да фикер алышу, проблемаларны хәл итү, нидер эшләр өчен, укучыларның билгеле бер күләмдә белемнәре булырга тиеш. Алардан башка алга таба үсеш булмый.

Мәктәп программалары кысаларында формалаштырасылары фундаменталь төшенчәләр белән системалы эшчәнлек алып бару зарур.

Белем бирү процессын оештырганда укытучылар укучыларның алган белемнәрне тормышта актив кулланышка кертә алуларын күздә тотарга тиеш була.

Теләсә нинди предмет кысаларында укучыларда 4 регулятив күнекмә формалаштырыла: укырга телим, нәрсәгә ирешәсен аңлыйм, чишү процессын төзи беләм, үз эшемне тикшерә һәм бәяли алам.

Шунлыктан, укытучыларга белем сыйфатын күтәрү механизмын тәкъдим итәләр.

- методик материалларны хокукый документларга туры китереп, даими яңарту;
- укытучыларның белемен күтәрү, яңадан әзерләү;
- яңа үлчәү берәмлекләрен кулланып, предмет, метапредмет, шәхескә кагылышлы нәтиҗәләрне тикшерү буенча комплекслы мониторинг уздыру;
- тикшерү нәтиҗәләре, аларны үткәрү чаралары турында барлык кешегә дә ачык мәгълүмат алу мөмкинлеге тудыру.

Барлык бу күнекмәләрне формалаштыру өчен, без үз эшчәнлегебездә уңышларга ирешү юлын, схемасын, эзлекле, системалы якын килү методын кулланабыз.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә нәрсәгә басым ясап эшлибез?

Текст белән эшләү күнекмәләрен үстерү. Иң элек текстның тибына игътибар итәбез.

Эшчәнлек ике юнәлештә алып барыла.

Беренчесе текстка таяну, эчтәлектәге мәгълүматны аерып алу, фикерне гомумиләштерә һәм кирәкле юнәлештә үзгәртә, куллана алу.

Икенчесе тексттан тыш биремнәр тектсның эчтәлеген, формасын аңлауга һәм бәяләүгә корылган.

Мәсәлән, укучыларның уку компетентлылыгы дәрәҗәсен билгеләү өчен мондый биремнәрне кулланырга мөмкин.

Биремнәрнең логик алымнары:

1нче дәрәҗә – белем: исемлек төзү, текстны өлешләргә бүлү, сөйләү, өлешләрне күрсәтү, исемнәрен атау.

2нче дәрәҗә – аңлау: аңлату, билгеләрен ачыклау, тасвирлау, биремнәрне, укыганнарны башкачаформалашиыру.

3нче дәрәҗә – куллану: гамәли куллану, эчтәлекне рәсемдә чагылдыру, проблемалы ситуацияне хәл итү.

4нче дәрәҗә – анализ: анализлау, тикшерү, эксперимент үткәрү, чагыштыру, аерманы ачыклау.

5нче дәрәҗә – синтез: уйлап табу, дизайн төзү, план төзүһәм план нигезендә сөйләү.

6нчы дәрәҗә – бәяләү: аргументлар тәкъдим итү, үз фикереңне яклау, дәлилләү, фаразлау.

Иң югары дәрәҗә – ул бәяләү. Башлангыч мәктәп укытучысы алдында гаять зур бурычлар тора: баланы шәхес буларак үстерү. Шул сәбәпле без башлангыч сыйныфта шушы күрсәткеч, критерийларга нигезләнеп, белем алу процессын оештырабыз.

Башлангыч сыйныф укучыларының уку грамоталылыгын PIRLS халыкара тикшеренүендә билгелиләр.

Башлангыч мәктәптә **PIRLS** уку һәм текстны аңлауны тикшерә. Бу тикшерүнең максаты урта звенога күчүгә әзерлек. Укырга өйрәтү, белем алу өчен уку, шәхси проблемаларыңны чишү өчен уку күнекмәләре урта звенода һәм өлкән сыйныфларда уку өчен нигез булып тора.

PIRLS тикшерүендә нәрсә тикшерәләр соң?

Укучыларның текстны ничек укуын һәм аңлавын тикшерәләр.

Тикшерүдә башлангыч сыйныфны тәмамлаучылар, Россиядә 4нче сыйныф укучылары катнаша?

Тикшерү 5 елга бер тапкыр уздырыла.

Тикшерү вакытында ике төрле уку күнекмәсе карала.

1) Әдәби тәҗрибә туплау.

2) Мәгълүматны үзләштерү һәм куллану.

Текстка сораулар 4 күнекмәне тикшерү өчен бирелә:

- мәгълүматны табу;
- нәтиҗәләр ясау;
- мәгълүматны гомумиләштерү һәм тиешенчә үзгәртә алу;
- эчтәлекне, тел үзенчәлекләрен һәм текст структурасын анализлау һәм бәяләү.

Укучыларга алдан мәгълүмат бирелә, ярдәмгә исемлектә

1) тел тойгысын үстерү, үз тел культурасын яхшырту теләге булдыру;

2) телдән дә, язмадан да мәгънәле, эзлекле һәм кагыйдәләргә туры килгән конструкцияләр төзү өчен тел чараларын сайлау;

3) тел системасының терминологик һәм концептуаль үзенчәлекләрен аңларга әзерлек.

Бу күнекмәләрне тикшерү өчен түбәндәге биремне тәкъдим итәргә мөмкин.

**1нче бирем.** Исемлекне кулланып, сорауларга җавап бир.

| | | **Походта ни өчен запас оек кирәк?** |
|---|---|---|
| 1. | Су. Эчәсе килүне бетерү өчен су запасы күп булырга кирәк | |
| 2. | Ашамлык: ашыйсы килүне бетерү, яисә пикник өчен | |
| 3. | Беренче ярдәм күрсәтү өчен медицина кулланмалары | |
| 4. | Бөҗәкләрдән саклану предметлары | **Поход вакытында ярдәм кирәк булса, нәрсә эшләргә кирәк?** |
| 5. | Запас оек, яки оекбаш | |
| 6. | Сыбызгы: адашкан очракта 3 кыска сызгырту | |
| 7. | Компас, карта | |

**2нче бирем.** *«Йомшак» сүзен төрле мәгънәдә кулланып, сүзтезмәләр яз. Диван, холык, ут сүзләрен куллан. Кайсы сүзгә мисал юк? Туры килгән сүзләрне мөстәкыйль билгелә.*

Йомшак___________мәгънәсендә «каты түгел».

Йомшак___________мәгънәсендә «кагылуга рәхәт».

Йомшак________мәгънәсендә «кырыс түгел, ачулану хисләре уятмый».

Мягкий________мәгънәсендә «юаш, тупас түгел».

Алдагы бирем текст эчтәлеген телдән һәм язма биргәндә башкалар фикерен дөрес, төгәл кабул итә белү күнекмәсе. Бу күнекмә балалар бакчасыннан «Ватык телефон» уены аша формалаша башлый.

**3нче бирем.** *Ни өчен театрга тиешле санда билетлар сатып алынмаганын аңлат.*

Әнисе улы Азатка телефоннан шалтыратып, кемнәргә билетлар аласын әйтеп яздырды һәм әтисенә билетлар алу өчен SMS хәбәр язып җибәрергә кушты. Әтисенең SMS хәбәрне укыгач, бер билет артык алганы ачыкланды. Ни өчен?

Азатның SMS хәбәре: Әтием миңа, Әлфия, апа һәм Алсу Зарифовнага театрга билет ал әле, зинһар диде.

Мондый хаталарны без стилистик хаталарга кертәбез. Чынлыкта, укучылар гаджетлар белән мавыккач, аралашу, сөйләм күнекмәсе шактый түбәнәйде. Әдәби матур сөйләм булдыру өчен, мәсәлән, шундый биремнәр башкарырга мөмкин.

**4нче бирем.** *Текстта җибәрелгән сөйләм хаталарын тап.*

Иртә белән мин якындагы каенлыкка барам. Язын каенлыкта шундый рәхәт һәм күңелле! Каен яфраклары аша үлән өстенә кояшның алтын нурлары төшә. Кошлар җырлый. Кошлар җырлары тирә-якка таралалар. Аста салкын чишмә ага. Мин чирәмгә утырам, су эчәргә әзерләнәм. Салкын чишмә суын эчү һәм тормыш шатлыгын тоеп, күкрәк тутырып сулыш алу нинди рәхәт!

Алдагы бирем тел системасының терминологик һәм концептуаль үзенчәлекләрен аңлауга әзерлекне формалаштыруга юнәлтелгән.

**5нче бирем.** *Җөмләдә аергыч булып килгән, берлек сандагы, иялек килешендәге исемне билгелә.*

Карангы урманга якты нур төште һәм агачка сарылган пәрәвездә үрмәкүчнең юлын күрсәтте.

Укучыларның сөйләм теле үсешенең югары булу татар теле һәм әдәби уку дәресләре өчен генә мөһим түгел. Функциональ грамоталы- лыкның башка компонентлары үсеше өчен дә сөйләм үсеше, уку грамоталыллыгы үзәктә тора. Моның шулай икәнлегенә төшенү өчен функциональ грамоталылыкның башка компонентларын күзаллап чыгу яхшы дәлил булып тора.

Математик грамоталылык – кешенең үзе тормышта математиканың ролен билгеләү һәм аңлау, төпле нигезле математик фикерләр әйтү һәм математиканы бүгенге һәм киләчәктә иҗади, кызыксынучан һәм фикерләүче шәхескә хас булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен куллану сәләте.

«Математик грамоталылык  ул индивидуумның математик фикер алышулар үткәрү һәм математиканы реаль дөньяның төрле контекстларында проблемаларны хәл итү өчен формалаштыру, куллану, интерпретацияләү сәләте.

Ул үз эченә математик төшенчәләрне куллана алу, төрлегамәлләрне, фактлар һәм инструментларны тасвирлау, аңлату һәм алдан күрә белү сәләте булу, күренешләрне ачык күзаллау. Ул кешеләргә тормышта конструктив, актив һәм уйланучан гражданга кирәкле карарлар кабул итәргә ярдәм итә.

2021 нче елгы PISA тикшерүләре нәрсәсе белән аерыла соң?

2021 елны халыкара тикшеренүләрнең яңа циклы башлану дип саныйлар.

Монда төп юнәлешләр – математик грамоталылык өстенлекле өлкә. Максат – математик грамоталылыкны бәяләү концепциясен камилләштерү.

Яңа юнәлеш – креатив фикерләү.

Яңа өлкәне кертү – укучыларның һәм укытучыларның шәхси иминлеген бәяләү.

Математик фикер алышуларны бәяләүгә аерым игътибар бирелә. Математика фикерләү һәм куелган проблеманы хәл итү арасындагы бәйләнешкә яңа караш:

Бу проблеманы хәл итү өчен математик яктан белемле укучы башта математик яктан табигый реаль дөнҗяви контекстында тәкъдим ителгән проблемаларны күрергә һәм аны математика телендә формалаштырырга тиеш. Бу үзгәртеп кору математик фикерләүне таләп итә һәм, бәлки, математик яктан грамоталы булу дигән сүзнең үзәк компоненты булып тора.

• Компьютерлы модельләштерү шулай ук үзәктә кала.

Математика грамоталылыкны бәяләү структурасы:

* Тест биремнәрендә кулланыла торган математик эчтәлек (функциональ грамоталылыкның предметлы үзәге): бәйлелек һәм үзгәрешләр (алгебра) киңлек һәм форма (геометрия) билгесезлек һәм мәгълүмат (Ихтималлылык теориясе һәм статистика) саны (арифметика)

• Когнитив процесслар (интеллектуаль эшчәнлек өлешләре), укучыларның тасвирлавы, нәрсәдер ясавы, контекстта бәйләнеш булдыруы, проблемалар тәкъдим итүе, математик грамоталылык нигезендә проблеманы хәл итү өчен кирәк булган ситуацияне, математик төшенчәләрне, фактларны, процедураларны куллану, үзгәртеп куллану, бәяләү нәтиҗәләре буенча фикер алышу.

• Контекст, анда проблема тәкъдим ителгән. Шәхси тормыш –кеше дөньясы, иҗтимагый тормыш – социум дөньясы, мәгариф/һөнәри эшчәнлек – һөнәрләр дөньясы, фәнни эшчәнлек – фән дөньясы.

Математик һәм табигый-фәнни грамоталылык нигезләрен үзләштерү.

** барлык гомуми белем бирү курслары (4, 8нче сыйныфлар)*

**TIMSS** тикшерүе – Trends in Mathematics and Science Study, 4, 8 һәм 11 сыйныфлар, 4 елга бер тапкыр 1995,..., 2015, 2019, 2023...

Контекстта шәхси тормыш, белем/ һөнәрләр, җәмәгать тормышы, фәнни эшчәнлек чагыла дидек.

Когнитив өлкә: фикерләрне, нәтиҗәләрне формалаштырып әйтеп бирә белү, белемне куллану, башкача үзгәртә алу, бәяләү, фикер алышу.

Эчтәлек өлкәсе: үзгәрешләр һәм бәйлелек, даирә һәм эчтәлекне бирү формасы, билгесезлек һәм мәгълүматлар, математик грамоталылыкның дәрәҗәсе.

Төп нигезләмәләр: Федераль дәүләт белес стандартына туры килү, мәгълүматларның актуальлеге, һәр сыйныфка бүленгән эчтәлеге, компьютер куллану.


Принциплар: мотивация (яше, кызыксыну, һәркем өчен мөмкин), тормышка ашыру мөмкинлеге, проблемалыны эченә алуы, чишү өчен вариантлар төрлелелгенә шарт булу.

Структурасы: текст – тасвирлама-вербаль, график, иллюстрацияләр белешмә материал, сораулар катлаулылыгы.

Бу күрсәткечләрдән чыгып, Галина Сергеевна Ковалеваның А. Эйнштейн сүзләрен һәрвакыт искә алуы искә төшерәбез: «Без җиңел юл белән үлчәтергә түгел, ә мөһим булган нәрсәләрне үлчәргә өйрәнергә тиеш...»

**TIMSS** тикшерүе буенча биремне дә карап үтик.

4нче сыйныфта математик грамоталылыкны тикшерү сорауга җавап бирер өчен ул фикерен башта телдән тупларга, анна язма бирергә тиеш.



Укучыга түгәрәк эчендә барлык яклары да тигез булган өчпочмак төзергә һәм кайсы нокталарны тоташтырганны күрсәтергә кирәк була.

Табигый-фәнни грамоталылык – әйләнәтирә дөньяны һәм кеше эшчәнлегенә керә торган үзгәрешләрне аңлау, шулай ук тиешле карарлар кабул итү өчен кирәкле күзәтүләргә һәм экспериментларга нигезләнгән нәтиҗәләр ясау өчен, фәнни методлар ярдәмендә өйрәнелергә һәм хәл ителергә мөмкин булган проблемаларны реаль тормыш хәлләрендә сайлап алу өчен табигый-фәнни белемнәрне куллану сәләте.

Табигый-фәнни грамоталылык – кешенең табигый фәннәр белән бәйле мәсьәләләр буенча актив гражданлык позициясен биләп тору сәләте, һәм аның табигый-фәнни идеяләр белән кызыксынуга әзерлеге.

Табигый-фәнни белемле кеше табигый фәннәргә һәм технологияләргә караган проблемаларны аргументланган фикер

алышуда катнашырга омтыла, бу аннан түбәндәге компетентлылык таләп итә:

– күренешләрне фәнни аңлату;

– яңа материалны үзләштерү, дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып - белү активлыгын үстерү, уку эшчәнлеген оештыра белү.

Безнең башлангыч сыйныф программаларда бу күнекмәләрне үстерүгә уку материалы бик аз кертелгән. Шуңа да карамастан, безнең Россия укучылары бу юнәлештә яхшы нәтиҗәләр күрсәтәләр.

Беренчедән, «Әйләнә-тирә дөнья» программасында TIMSS тестларында булган әйбернең якынча 40% ы юк: физика һәм химия юк диярлек; үрчү һәм Мирас мәсьәләләре каралмый.

Икенчедән, Россия программасы күләме (якынча 50 сәгать 4 сыйныфта) Сингапурда, Корея һәм Япония илләре программасыннан якынча ике тапкыр кимрәк, һәм Португалиядән өч тапкыр азрак.


Өченчедән, «Әйләнә – тирә дөнья» программасы TIMSS тестлары табигый-фәнни грамоталылыкның, шулай ук укучыларның уку грамоталылыгы үсешенең яхшы формалашкан булуын таләп итә, чөнки биремнәргә җавап язар өчен сөйләм күнекмәсе үсеше югары нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеге бирә.

Бер мисал карап үтик.

Азат үз бакчасында үрмәкүчләрдән котылырга тели. Ә Самат моның начар идея булуын һәм үрмәкүчләрнең әйләнә-тирә мохиткә мөһимлеге әйтте. Укучыларга түбәндәге бирем тәкъдим ителде.

**Бирем.**

– Ни өчен бакчада үрмәкүчләр булу мөһим? Бер сәбәбен дәлилләп языгыз.



Финанс грамоталылыгы 5нче сыйныфта тикшерелә, әмма башлангыч сыйныфларда әйләнә-тирә дөнья дәресләрендә әзерлек эше башлана, программада бу темага сәгатьләр бирелгән.

**PISA** тикшереүендә финанс грамоталылыгы финанс терминнарын, төшенчәләрен белү һәм аңлау, финанс тәвәккәллек, куркынысызлык, шулай ук шәхеснең һәм җәмгыятьнең финанс иминлеген яхшыртуга ярдәм итүче төрле финанс хәлләрендә

нәтиҗәле карарлар кабул итү өчен кирәкле күнекмәләр, мотивация һәм ышанычны үз эченә ала.

Финанс грамоталылыгы: эчтәлек, танып-белү эшчәнлеге һәм контекстлар.

Эчтәлеге: акча һәм операцияләр, алар белән планлаштыру һәм идарә итү, финанслар куркынычсызлыгын һәм бүләкләүне тәэмин итү, финанс мохите.

Танып белү эшчәнлеге: финанс мәгълүматын ачыклау, контексттагы мәгълүматны анализлау, финанс проблемаларын бәяләү, финанс белемнәрен куллану һәм аңлау.

Контекстлар: мәгариф һәм эш, йорт һәм гаилә, шәхси чыгымнар, ял һәм ял, җәмгыять һәм шәхес.

"Валюта" вәзгыяте, мәсәлән, иҗтимагый һәм шәхси берләшмәләр.

– Марина, син бу тамгаларны ничек аңлыйсың? – дип сорадым.

– Бу сәер билгеләр нәрсә өчен кирәк?

– Бу билгеләр төрле илләрнең акчаларын сурәтли, — дип җавап бирде Марина.

– Һәр билге-ул ...

**«Дима чыгымнары» (шәхси чыгымнар, ял, хәл)**

– Күп акча сарыф иттең инде, — диде Настя.

**«Ике гаилә» (өй һәм гаилә) хәле**

– Бездә бюджетлар аерыла, — дип билгеләп үтте Катя.

– Минемчә, бу, беренче чиратта, гаиләләребез төрле булуы белән бәйле.

Бу мисаллар гади һәм ачык тел белән түбәндәге мәсьәләләрне яктырта, шәхси финанс планлаштыру, чыгымнар һәм гаилә керемнәрен ничек саклап калу һәм арттыру, кредитлау һәм мөмкин булган куркынычсызлыклар, мобиль түләүләр һәм мошенниклардан саклану, салымнар, пенсия, финанс махинацияләреннән яклау буенча күнекмәләр формалаштыруга юнәлтелгән.

Ә глобаль компетенцияләрне ничек күз алдына китерәбез соң?

Глобаль компетентлылык – бу укыту дәвамында күпкырлы максатны күзаллау сәләте. Глобаль компетентлы шәхес

җирле, глобаль проблемаларны һәм мәдәниятара багланышлар мәсьәләләрен өйрәнергә, төрле карашларны аңларга һәм бәяләргә, башкалар белән уңышлы һәм ихтирамлы хезмәттәшлек итәргә, шулай ук тотрыклы үсеш һәм күмәк иминлекне тәэмин итү өчен җаваплы эшләргә сәләтле.

Глобаль компетентлылык структурасы:

– *белемнәре (когнитив тест белән бәяләнә);*
– *когнитив осталык (когнитив тест белән бәяләнә);*
– *мөнәсәбәтләр (анкета белән бәяләнә);*
– *кыйммәтләр (бәяләүдән тыш).*

Глобаль компетентлылыкка ия булу сәләте нәрсәдә чагыла соң?

– глобаль характердагы һәм мәдәниара бәйләнештәге мәсьәләләрне һәм ситуацияне төрле күзлектән карап тикшерү һәм бу хәлләрдә нәтиҗәле эш итү;
– мәдәни, дини, сәяси һәм башка аерымлыкларны аңлау, йогынты ясый алу, кабул итү, фикерләр һәм карашлар;
– яңа материал-ны үзләштерү, дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү уку эшчәнлеген оештыра белү.

Функциональ грамоталылыкның соңгы компоненты креатив фикерләү. Ул идеяләрне тормышка ашыру, бәяләү һәм камилләштерү процессында нәтиҗәле катнашу төшенчәсен, инновацион (яңа, новатор, оригиналь, стандарт булмаган, гадәти булмаган) һәм нәтиҗәле (нәтиҗәле, нәтиҗәле, экономияле, оптималь) карарлар, яки яңа белем, эффектлы (тәэсирләндерүче, рухландыручы, гаҗәеп, гаҗәеп һ.б.) гыйбарә белдерүне аңлата.

PISA тикшеренүләрендә креатив фикерләүне бәяләү моделе.

Креатив фикерләүне бәяләү функциональ грамоталылыкны бәяләүдә яңа юнәлеш. Уздырылган апробация нәтиҗәләре күрсәткәнчә, тәкъдим ителгән биремнәр системасы 5 нче, 7 нче сыйныф укучылары өчен бик көчле һәм аңлаешлы итеп эшләнгән. Легендалар һәм биремнәр структурасы гомумән алганда, эчтәлеккә туры килә. Экспертлар фикеренчә, күп кенә биремнәр кызыклы һәм файдалы, ләкин кайберләрен камилләштерергә кирәк.

Башлангыя сыйныф укучыларына шундый характердагы биремнәрне тәкъдим итәргә мөмкин.

*1нче бирем.*

– Даруларны даруханәдә табиб рецепты буенча сатып алганда, сез нәрсәгә игътибар итегез?
*2нче бирем.*
– Сезнең балада баллы ризыкларга аллергия, кондитер әйберләре сатып алган вакытта, сез нәрсә эшлисез?
*3нче бирем.*
– Дистанцион программа буенча Сез укуларга язылдыгыз. Уку башлангач Сезнең беренче гамәлләрегез нинди булыр?

Игътибар итсәк, биремнәр укучыларны уйландыра, ситуатив даирәгә куя, укучы эзләнә, фикер йөртә. Менә бу күнекмәләр барысы да, һичшиксез, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә дә башка предметлар белән беррәттән системалы алып барыларга тиеш. Әлбәттә, эшне тиешле дәрәҗәдә оештырсак, эш документларында дөрес күрсәтсәк, укучының функциональ грамоталы шәхес булуына ирешә алачакбыз. Һәм инде ул очракта белем күрсәткече дә югары булыр.

Күргәнебезчә, предмет нәтиҗәләре генератор булып кала, метапредмет һәм шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр предмет нәтиҗәләреннән үсә. Предмет нәтиҗәләре әйләнә-тирә дөнья күренешләре турында күзаллаулар булдыра, функциональ грамоталылыкның белем-мәгълүмати каркасын формалаштыра.

Иң мөһиме, бездә предметара чикләрне бетерү кирәк. Предметара элемтәне көчәйтергә, предметларны төрле формаларда интеграцияләргә өйрәнү зарур.

Проект эшчәнлеге аңлы социаль-кирәкле эшчәнлектә белемнәрне тормышка ашыру өчен шартлар тудыра.

Фикеребезне йомгаклап әйтсәк, функциональ грамоталылыкны ничек формалаштырабыз соң?

Әлбәттә, белем бирү процессында нәтиҗәле педагогик тәҗрибәләрне кулланабыз.

Нинди тәҗрибәләр?

Укучыларның уку эшчәнлеген оештыруны башлап җибәрүче, аларны уку эшчәнлегенә этәрүче һәм бу эшчәнлекнең мәгънәләрен ачыклаучы уку-укыту ситуацияләре булдыруны күздә тоткан биремнәр системасы:

– тәҗрибә булдыру, сабак алу, проблемаларны хәл итү, карарлар кабул итү, үз-үзеңне тәрбияле тоту күнекмәләре формалаштыру;
– аралашу күнекмәләре, яки уку хезмәттәшлеге, парларда һәм кече төркемнәрдә эшне оештыруны таләп иткән биремнәр;
– эзләнү активлыгын үстерү, уку-укыту тикшеренүләре, проектлар;
– укучыларның бәяләү мөстәкыйльлеге, үз - үзеңә һәм үзара бәяләү буенча биремнәр: кейслар, рольле уеннар, диспутлар һ. б.

Функциональ грамоталылыкны бәяләү өчен биремнәрнең үзенчәлекләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:
– фән өлкәсеннән читтә куелган һәм предмет белеме ярдәмендә хәл ителә торган бурыч, мәсәлән, татар теле предметы яки башка предметлар буенча;
– һәр биремдә, кагыйдә буларак, укучыга аңлаешлы тормыш ситуациясе тасвирлана;
– биремнәр контексты көндәлек тормышта килеп туган проблемалы хәлләргә якын;
– хәл ителә торган проблема чишү юлын аңлы, уңышлы сайлау һәм проблеманы чишү процессында үз-үзеңне тотуны күрсәтә;
– сораулар гади, аңлаешлы, кыска бирелә;
– гадәти телдән фән өлкәсенә (татар теле һәм әдәби уку, математика, әйләнә-тирә дөнья һ. б. тәрҗемә итүне таләп итә.)
– рәсемнәр, таблицалар кулланыла.

Функциональ грамоталылыкны формалаштыру һәм бәяләү өчен биремнәрне сайлап алуның төп критерийлары:
– контекстта һәрвакыт ситуация булуның әһәмияте;
– гадәти тел ярдәмендә формалаштырылган бурычларны предмет өлкәсе теленә тәрҗемә итү зарурилыгы;
– бурычларны формалаштыруның яңалыгы, аларны хәл итү ысулларында билгесезлек.

Хөрмәтле коллегалар, менә безнең укучыларыбыз мондый дәрәҗәдәге биремнәрне хәл итә алсын өчен, без һәр бирем белән эшлибез, конкрет планлаштырылган нәтиҗәләрдән ориентлашып, тормыш ситуциясенә күчерәбез. Һәр дәрескә алын-

ган белемнәрне тикшерү һәм тикшерү өчен биремнәрне, һәр бүлеккә, темага һ. б. кертәбез.

Без заманча мәгариф системасында укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштыруны һәр уку предметы контекстында хәл ителергә мөмкин булуын күздә тотып белем бирү процессын оештырабыз.

Функциональ грамоталылыкны формалаштыру – катлаулы, күпкырлы, озак вакытлы процесс. Төрле заманча белем бирү технологияләрен берләштереп, оста итеп, кирәкле нәтиҗәләргә ирешеп була.

**Кулланылган әдәбият.**


1. Государственная программа Российской Федерации «Развитие образования» (2018–2025 годы) от 26 декабря 2017 г.
2. Качество общего образования в российской школе: по результатам международных исследований / науч. ред. Г.С. Ковалева. – М.: Логос, 2006. 408 с. – (Актуальные вопросы развития образования). – PISA-2003.
3. Примерная основная образовательная программа начального общего образования (ОДОБРЕНА решением федерального учебно-методического объединения по общему образованию - протокол от 8 апреля 2015 г. № 1/15).
4. Указ Президента РФ от 07 мая 2018 года №204 «О национальных целях и стратегических задачах развития РФ на период до 2024 года».
5. Указ о национальных целях развития России до 2030 года (от 21 июля 2020 года).
6. Федеральный государственный образовательный стандарт начального общего образования. — М.: Просвещение. 2011.

**Кушымта**

Дәреснең темасы:
**«ЯЗГЫ КАНИКУЛЛАР»** темасына хикәя төзү.

Лаеш муниципаль берәмлегенең
МБГБУ «Лаеш шәһәре 1нче гимназиясе»нең туган (татар) тел
укытучысы **Әхмәтова Гөлинә Раушан кызы**

**Дәреснең максаты:** үзләштергән лексик материалны кулланып, «Язгы каникулда» темасына текст төзү күнекмәсен үстерү.
**Җиһазлау:** презентация, ноутбук, экран, проектор, калтыравыклар.
**Дәрес тибы:** Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе.
**Дәрес планы:**
I. Оештыру өлеше:
1) исәнләшү, хәл сорашу; 2) һава торышы турында сөйләшү; 3) уңай психологик халәт тудыру.
II. Актуальләштерү:
1) фонетик зарядка;
2) видеоязма карау;
3) дәреснең темасын ачыклау;
4) уку максатын билгеләү.
III. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.
IV. Рефлексия.
V. Өй эше.
VI. Йомгаклау
**I. Оештыру өлеше.**
– Исәнмесез, укучылар.
– Хәерле көн!
– Тәрәзәгә карагыз! Бүген көн нинди?
– Бүген көн җылымы? (Юк, бүген көн салкын.)
– Урамда җил исәме? (Әйе, җил исә яки юк, җил исми)
– Кар явамы? (Әйе, кар ява яки юк, кар яумый)
– Бүген сез туңдыгызмы? (Әйе, без туңдык яки юк, без туңмадык)
– Менә монда кояш элеп куям, дәрес дәвамында сезгә җылылык биреп торсын.
– Балалар утырыгыз.
**II. Актуальләштерү.**
1. Фонетик зарядка.
– Ә хәзер авазлар белән эшләп алабыз.

– Башта мине күзәтәбез. (Укытучы көзгесез бер авазны әйтә, аннан шул ук авазны көзгегә карап әйтеп күрсәтә).

– Аннан үзегез шул авазларны ике ысул белән кабатлагыз.

– Башладык: [ә], [ү], [ө], [къ], [гъ], [h], [w], [җ]

– Үзегез генә кабатлагыз.

2.Видеоязма карау.

– Хәзер укучылар сез видеоязма караячаксыз.

– Ул нәрсә турында булыр? (Видео карау)

– Каян белдегез? (Кар эри, чәчәкләр, кошлар, җырда әйтелә...).

– Укучылар кайда? (Урамда).

– Алар ни өчен, мәктәптә түгел дип уйлыйсыз? (Чөнки аларда каникул).

– Хәзер бүгенге дәреснең темасын әйтеп карагыз (Язгы каникуллар).

– Килешәсезме?

– Әйе, димәк теманы хор белән әйтик.

– Сез язгы каникулны көтәсезме?

– Күзләрегезне йомып, язгы каникул турында хыялланып алыгыз әле.

– Мин сезнең хыялларыгызны сорамыйм, дәрес азагында безнең эшләр белән туры килерме икән, чагыштырырсыз.

3.Сүзлек эше.

hава - воздух
яз - весна
сыерчык - скворец
сыерчык оясы - скворечник
чәчәк - цветок
кояш - солнце
җылы - теплый

– Ә хәзер бүген дәрестә булачак сүзләр белән эшләп алыйк.

– Сүзләрне укып чыгыйк.

– Тәрҗемәсен әйтегез.

*Сүтезмәләр белән эш.*

– Әйдәгез, рәсемнәргә карагыз.

– Язгы каникулда балалар нишли? (уйный, саф hавада йөри; кораблар җибәрә, сыерчык оялары ясый, сыерчыкояларын элә, умырзаяларны күзәтә, кошлар кайта).

– Тәрҗемә итегез! (1. Рәсем чыга, татарча җавап әйтәләр, экранга карыйлар, уйлыйлар, саф hавада йөри, урамга чыга,

тәрҗемә итегез. 2. Рәсем – татарча җавап – язу татарча – перевод.)

– Бу сүзләрне – сүзтезмәләрне барыгыз да аңладымы?

– Кем бу сүзләрне аңлады?

**III. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.**

**1нче бирем.**

– Укучылар, хәзер төшеп калган сүзтезмәләрне өстәп, җөмлә төзибез.

– Мин _____ ______ яратам!

– Җөмләне эчтән укыгыз. (1. Саф һавада йөрергә. 2. Кораблар җибәрергә. 3. Сыерчык оялары ясарга. 4. Сыерчык оялары элергә. 5. Умырзая чәчәкләрен күзәтергә. 6. Кошлар кайтканын карарга)

– Әйдәгез, беренче төркемнән — 3 кеше кычкырып укысын, ә хәзер икенче төркемнән — алар әйтмәгән 3 җөмләне укыгыз.

**2нче бирем. Диалог.**

– Ә хәзер сөйләшеп алырбыз. Диалогны тыңлагыз, үзегезгә рольләр сайлагыз.

– Кемнәр катнашты?

– Малайларның исемнәрен үзегезнең исемнәр белән алмаштыра аласыз.

– Ярым тавыш белән сөйләшеп алыгыз.

– Әйдәгез кем кычкырып сөйләшеп карый? Игътибар белән тыңлагыз. Кем сайлаган ролен яхшы башкарыр? Кем сезгә ошар?

– Сәлам, Гали!
– Сәлам, Ринат!
– Син кая барасың?
– Мин урамга чыгам.
– Анда нишлисең?
– Мин суда кораб йөздерәм.
– Ә син нишлисең?
– Мин сыерчык оясы эләм.
– Әйдә, киттек.
– Кем сезгә ошады? Ни өчен? (Үзара бәяләү)

*Физкультминутка*

– Уяндык!
– Кояш чыкты!
– Урамга чыктык!
– Җил исә!
– Тамчылар тама!
– Умырзая чәчәк ата.

**3нче бирем. Сөйләм телен үстерү.**

– Без сезнең белән рамкалар һәм лупа кулланып, рәсемдәге алгы һәм арткы пландагы предметларны, кешеләрне карарбыз.

– Мин күрсәткән предметны сез әйтәсез (кояш, сыерчык оясы, ничә кош), ә хәзер рамкалар белән калган кошларны үзегездә карагыз. Ничә кош?

– Балаларны карагыз.

– Ә хәзер лупаларны алдык. Арткы планны карыйк.

– Артта нәрсә күрәсез? (Агачлар)

– Өстәлдәге рәсемдә карагыз.

– Агачта сыерчык оялары бармы?

– Хәзер алга күчик?

– Алда нинди чәчәкләрне күрәсез?

– Алар нинди төстә? (Ак)

– Рәсем буенча сездә нинди теләк туды? (Яз килүен телибез.)

– Каникулны көтәсезме?

– Әйдәгез, хәзер үзебезнең теләкләр турында сөйләп карыйк.

**4нче бирем. Текст төзү** (Текстны рәсемнәр белән тулыландыру, сөйләү).

– Сез хәзер бергәләп төркемнәрдә текст төзерсез.

– Буш урыннарга туры килгән рәсемнәрне ябыштырыгыз.

– Аннан рәсемнәрне сүзләр белән атап, текстны төркемдә укыгыз.

– Ә хәзер кычкырып кем укый? (Бер укучы тотып тора, икенчесе укый)

– Кемнең исендә калды? Кем сөйли ала? Онытканда, карап алсагыз да ярый.

– Тагын бер кат укыйлар.

– Рәхмәт, сезгә текст ошадымы? Каникулда кемнең ул эшләрне эшләп карыйсы килә? (Кул күтәрәләр)

**IV. Рефлексия.**

1) Безнең бүген нинди тема булды? (яисә бүген нинди тема үттек?)

– Нинди сүзләрне истә калдырдык?

– Аларны ничек кайда кулланырсыз?

– Кем язгы каникулда шулай ял итәсе килә?

2) Дәрестә кем үзенә «5»ле куя? Ни өчен? «4»ле? «3»ле?

**V. Өй эше.**

Дәреслектәге «Язгы каникуллар» тексты.

1) дәреслекнең 81 нче битендә текстны кабат укып, Гали белән Ринатның диалогын үзгәртеп сөйләргә.
2) https;//sch2289.wixsite.com/my-site-1.
3) дәрестә кабатланган сүзләр белән текст төзеп килергә.

**VI. Йомгаклау.**

– Сезгә бүген дәрес ошадымы?

– Дәрес башындагы хыялларыгыз тормышка аштымы?

– Әйдәгез, кемгә дәрес ошады, менә бу кәрзингә умырзая чәчәкләрен җыйыйк.

– Чәчәкләр һәм кояш сезнең кәефегезне күтәрсен, җылы язны тизрәк җиткерик.

**Тема: Зәкәрия Әхмәрев «АГАЧЛАР ДА АВЫРЫЙ»**
хикәясе өстендә эш

Яр Чаллы шәһәренең «Аерым предметлар тирантен өйрәнелә торган 35 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»
МАГББУ югары категорияле туган (татар) тел укытучысы
**Хөсниярова Гөлнәзирә Наһис кызы**

**Максат:**

1) Әсәрнең эчтәлеге аша табигать һәм кешенең аерылгысыз бербөтен икәнлегенә төшендерү;

2) фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү;

3) табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһаз:** мультимедиа, презентация, интерактив такта, тарату материаллары, рәсемнәр, үсемлекләр.

**Дәрес планы**

**1. Оештыру, мотивлаштыру этабы.**

**Уңай психологик халәт тудыру**

Исәнмесез, диеп башлыйм әле
Танышу бит шулай башлана.
Бер елмаю дәва мең авырудан
Дуслык елмаюдан башлана.

– Әйдәгез бер-беребезгә карап, елмаеп дәресне башлап җибәрик.

*Стеналарда танкеткалар эленеп тора, балалар ярты-лаш түгәрәккә басканнар.*

– Балалар, дөрес, матур сөйләшү өчен, **тел шомартып алыйк әле. Сезнең алдыгызда танкеткалар — икеюллык кыска шигырьләр:**

– Мин әйтәм, аннан сез кабатлыйсыз:
1. яшел
агач үсә (2 тапкыр)
2. агач
шиңә корый
3. су сибәргә
кирәк
4. агачка
без ярдәм

– Балалар, ничек уйлыйсыз, болар җөмләләрме? (*Юк, җөмләләр түгел*)

– Ни өчен юк дип уйлыйсыз? (*кагыйдәне искә төшерү*) (*Җөмлә баш хәрефтән языла, ахырында нокта куела*)

– Бик дөрес. Әйдәгез әле, бу танкеткалардан җөмләләр төзик. (*Балалар стенага куелган танкеткаларны төзәтеп, парлап җөмләләр төзиләр, берсе баш хәрефен, икенчесе маркер ярдәмендә тыныш билгеләрен куя*).

**2. Актуальләштерү.**

– Укучылар, бу җөмләләр сез укыган кайсы әсәргә туры килә? («*Агачлар да авырый*»)

– Аның авторы кем? (Зәкәрия Әхмәрев) (*тактага элеп куям*)

– Бик дөрес. Әйдәгез әле бергәләп кабатлыйк. **(Укучылар белән бергәләп исем, фамилиясен кабатлыйбыз)**

**Зәкәрия Әхмәрев** (Зәкәрия Яхъя улы Әхмәрев, 1924 нче елның 18 нче августында Оренбург өлкәсе Карабалык авылында туа. — журналист, өлкәне өйрәнүче, педагог. Муса Җәлил, Шамил Госманов һәм башкалар иҗатына багышланган мәкаләләр авторы. 1990 нчы елның 4нче июнендә (65 яшендә) Оренбург өлкәсе Тоз-Түбә районы Карабалык авылында вафат була).

**А) Хәзер текстның эчтәлеге буенча белемнәрегезне тикшереп алырбыз.**

– Сезнең алдыгызда яшел кәгазьләр, ачыгыз. Анда җөмләләр, аларны текст эчтәлеге буенча урнаштырырга кирәк. (*Укучылар кычкырып укый, мин тактага тезә барам)*

– Хикәянең эчтәлеген аңлагансыз. Бик дөрес. Ә бу җөмләләр безгә дәрес барышында ярдәмчеләр булырлар.

– Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшербез? (*Агачларның авыруы, аларны тәрбияләргә кирәклеге турында*)

Максатыбыз: табигать белән кешенең аерылгысыз бербөтен икәнлегенә төшенү.

**3. Яңа белемнәрне беренчел үзләштерү.**

– Укучылар, тактада агач рәсемнәре — **(*тактада ике агач рәсеме*)**

– Беренче агачка менә бу җөмләләрнең кайсы туры килә? **(*Яшел агач үсә*) (*тактага беркетәм*)**

– Икенче агачка кайсы туры килә? **(*Агач шиңә, корый*) (*тактага беркетәм*)**

– Бик яхшы. Агачларга исем куштык.

– Укучылар, хикәядә кайсы агач турында сүз бара әле? Исеме ничек? (*А*гачның исеме- алмагач)

– Ул безнең якта үсәме? (Әйе, ул безнең якта үсә.)

**Б) Балалар, экранда нәрсәләр күрәсез? (слайд)**

– Укучылар, аптечка ни өчен кирәк?

(*кеше авырганда, андагы даруларны куллана, яраларны бәйләү өчен бинтлар бар*)

Без авырганда кем ярдәмгә килә? (*Без авырганда табиблар ярдәмгә кил*ә).

– **Укучылар, ә хикәядә агачка кем ярдәмче булды?** (*Әти ярдәмче булды).*

**5.Яңа белемнәрне үзләштерүне беренчел тикшерү.**

– **Ә хәзер, әйдәгез, төркемнәрдә эшлибез. Әтигә характеристика бирик.**

**Беренче төркем: Агач коруын әтисе ничек аңлата?** (Шул сүзләрне тексттан таба).

**Икенче төркем: Агачны ничек үстерергә була?** (Әтинең сүзләрен тексттан таба).

**Икенче төркем укыганнан соң тәҗрибә үткәрү.**

– Балалар, әйдәгез әле бер тәҗрибә (опыт) үткәреп карыйк. Мине тыңлагыз: хәзер менә бу өстәл янына чыгыгыз һәм парлап басыгыз.

Минем белән бергә эшлибез. Бер укучы сулы стаканны, икенче укучы җирле стаканны ала. Сулы стаканга әкрен генә җирне бушатыгыз. Нәрсә күрәсез? (*су куыклары, һава күтәрелә*)

**Әтисенең әйткән сүзләренә туры киләме?** *(тамыр һава сулый)*

– Сез зур сыйныфларда биология дәресләрендә моның турында тагын да күбрәк белерсез әле.

Укучылар, агачлар турында этисенә кем сораулар бирә һәм алар өчен борчыла? (Рәмилә)

– Әйдәгез, кызның сыйфатларын ачыклыйк.
***Төркемнәрдә эш.***

**Сезнең алдыгызда әзер җөмләләр**, шуларга җавап язарга кирәк.

Беренче төркем: Рамилә этисенә сораулар бирә. Кыз нинди?___(*кызыксынучан) (любознательная)*

Икенче төркем: Рамилә агач өчен борчыла. Кыз нинди?________(*кайгыртучан)(заботливая*)

– Рәхмәт, укучылар, бик яхшы. *(укучылар белән бергәләп кабатлау, җөмләләр төзү, тексттан таптыру).*

– Шулай итеп, хикәядә агачны кемнәр үстерә?

– Балалар, ә тормышта агачларны кем үстерә, кемнәр ярдәм итә?

– Рәхмәт, укучылар, бик яхшы.

– Ә хәзер сезнең игътибарыгызга мультфильмнан өзек тәкдим итәм.

– Кызның этисе кәҗәне куып дөрес эшләдеме?

– Ни өчен? (Кызның этисе дөрес эшләде, чөнки ул агачны кимерде)

– Ә кемнең игътибарсызлыгы аркасында кәҗә бакчага кергән?

– Кем капканы ачык калдырган?

**Икенче өзекне карыйк.**

**Рәмилә ни өчен кәҗәне кертми? Агачны кәҗә кимерә.**

– Балалар, ә тормышта агачларга кемнәр, нәрсәләр зыян китерә?

Тагын нәрсәләр аркасында агачлар корый, авырый? (*Кеше сындыра, яшен суга, бөҗәкләр ашый, янгын чыга, көчле җил, ураган сындыра. (рәсемнәрне эләм)*

Яшел агачны үстерү өчен нишләргә кирәк?

Агач корымасын өчен нишләргә кирәк?

Әйдәгез, белешмә (памятка төзик) Беренче төркем - яшел агачны үстерү, икенче төркем - агач корымасын өчен.

**Белешмә. Яшел агачны үстерү**
**1нче төркем**

1. Агачка су сибегез.
2. Агачның төбен йомшартыгыз.
3. Агачның аскы өлешен агартыгыз.

**агач корымасын өчен.**
**2нче төркем**

1. Агачка су сибегез.

2. Агачның төбен йомшартыгыз.
3. Агачны сындырмагыз.
4. Агачны дәвалагыз.

**Су сибәргә кирәк** — (Укучылар әйтә бара, тактага язмалар эленә).

**Агач төбен йомшарт** — (Укучылар әйтә бара, тактага язмалар эленә).

Укучылар, агачларга тагын кайларда ярдәм итеп була? (Мәктәптә, урманда, паркларда) Чәчәкләргә, гөлләргә ярдәм кирәкме? Кайсы гөлгә ярдәм кирәк?

Тактага: **Без — агачка ярдәм.**

Ә сыйныфта кайсы гөлгә ярдәм кирәк? 2 бала су сибә, йомшарта. (*калганнары яннарында карап тора*)

Афәрин, булдырдыгыз, балалар, гөлләребез бик матур булып үсәр.

**5. Белемнәрне үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү.**

– Укучылар, без сезнең белән агачларны тәрбияләргә кирәклеген, авырулары турында сөйләшәбез, хикәядән дә укыдык.

– Агачларның ни өчен кирәклеге турында әйтмәдек бит әле.

– **Җөмләләр төзегез.** Кем беренче үз җөмләсен укый? (Агачлар һаваны чистарталар. Агачлардан өйләр төзиләр. Агачлар җимеш бирәләр. Агачлардан дару ясыйлар. Агачлар матурлык бирәләр. Агачлардан кәгазь ясыйлар.) *Хаталарны төзәтәм.*

– Рәхмәт, балалар.

– Нәтиҗә.Табигатьне сакларга кирәк!

**Рефлексия, бәяләү этабы.**

– Бүген дәрестә нәрсәләр өйрәндек? Автор нәрсәгә өйрәтә? (*Агачлар кешеләргә бик кирәк. Алар чиста һава бирәләр, матурлык ясыйлар, тәмле җимешләр дә бирәләр. Әгәр алар яраланса, аларны бәйләп куярга кирәк. Су сибәргә, төпләрен йомшартырга кирәк. Аларны сындырырга ярамый.*)

– Әйе, балалар, сез бик дөрес нәтиҗә ясадыгыз.

Сез дәрестә бик тырышып эшләдегез, афәрин. Хәзер үзегезнең күңелезгә якын танкетканы сайлагыз да конвертка салыгыз. (Интерактив тактада эш)
үстерик гөл, чәчәк, табигатьне, саклыйк, агачлар, бик кирәк.

– Рәхмәт, балалар.

Табигатьне сакларга кирәк! Зәкәрия Әхмәрев та **«Агачлар да авырый»** әсәре белән шуны әйтергә теләгән.

Дәрес тәмам, укучылар, рәхмәт сезгә, уңышлар телим.

**Работа с текстом «ШУНДЫЙ ЗУР БАЛЫК!»**

3нче сыйныф, рус төркеме
Казан шәһәре, Авиатөзелеш районы «33 нче гимназия»
МБББУ туган (татар) теле укытучысы
**Карпухина Наилә Илһам кызы**

*Мои ученики будут узнавать новое не от меня,
они будут открывать это сами. Моя задача
помочь им раскрыться и развивать собственные идеи»*
*Н.Г.Песталоцци*

**Цель:** развитие читательской грамотности учащихся на уроке родного языка.

**Задачи:**

Формировать умение

- *находить в тексте информацию*
- *интерпретировать текст*
- *формулировать вопросы*
- *осмысливать и оценивать прочитанное*
- *связывать информацию в тексте, со знаниями из других источников*
- *строить развернутые высказывания*
- *сотрудничать*

Развивать способность применять полученную в процессе чтения информацию в разных ситуациях.

Сопоставлять утверждения, сделанные в тексте, со своими представлениями о мире.

**Планируемые результаты:**

*Предметные результаты:* умение самостоятельно читать, понимать, анализировать текст, отвечать на вопросы, задавать свои вопросы.

*Метапредметные результаты:* изучение окружающего мира.

*Познавательные универсальные учебные действия:* умение работать с текстом: понимать причинно-следственные связи, основную мысль текста для ответа на поставленные вопросы.

*Регулятивные универсальные учебные действия:* ставить цели, планировать пути их достижения.

*Коммуникативные универсальные учебные действия:* умение взаимодействовать с одноклассниками, сотрудничать и приходить к общему решению в совместной деятельности, учитывать различные мнения, аргументировать собственную точку зрения.

**Личностные результаты:** взаимопомощь, доброе отношение к одноклассникам.

**Средства обучения:** учебное пособие «Сәлам!», дидактический раздаточный материал, презентация.

## Ход урока

**1.Организационный момент.**

1) Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләрен сораша. Уңай халәт тудыру өчен, балалар бер-берсен сәламлиләр. Парларны табып капма-каршы басалар һәм сөйләшәләр:

- Сәлам, дустым! (кул бирешәләр)
- Хәлләр ничек? (җилкәләренә кагылалар)
- Кайда булдың? (колактан җиңелчә тарталар)
- Мин сагындым! (кулны йөрәккә куялар)
- Син килдең! (кулларны җәяләр)
- Мин бик шат! (кул бирешәләр)

2) Укытучы укучылардан дәрестә кирәк булачак лексик берәмлекләрне һәм структураларны кабатлата.

**2. Дотекстовые задания (подготовка к самостоятельному чтению).**

Учащимся предлагается

а) посмотреть на картинку, назвать слова по-татарски, вспомнить лексику, которую здесь можно применить.

ә) перевести предложения, в которых есть лексика, встречающаяся в тексте:

Әтием Идел буена китте.
Мин каты йоклыйм.
Без Идел буеннан кайтабыз.
Мине әни уятты.
Ул бер үзе балыкка җыенды.
Туганнар белән балык тота.
Барыбер аңа ышанмый. һ.б.

б) укучыларга үзләренә рәсем буенча сүзтезмәләр һәм кечкенә җөмләләр төзергә тәкъдим ителә.

в) учащиеся отвечают на вопрос «О чем мы сегодня будем читать?» (выводится тема урока «На рыбалке»)

г) укучыларга, дәреслекләрне ачып (3 нче сыйныф, 104 нче бит), текстның башын укырга кушыла, тексттан алынган сүзләрне тәрҗемә итәргә, дәвам итеп карарга тәкъдим ителә: *якшәмбе, балык тотарга, зур балык алып кайттык, җомгага кадәр ашадык, туганнар булыштылар, икенче дүшәмбегә кадәр.* Аннары текст нәрсә турында булыр икәнен сораша. Укучылар фаразлыйлар.

**3.Текстны мөстәкыйль уку.**

Укучылар текстны эчтән укыйлар, таныш лексикага һәм структураларга нигезләнеп текстның эчтәлеген аңларга тырышалар.

Кемнең фаразлавы дөрес икәнен тикшерәләр. (Выясняют, чье предположение оказалось ближе к тексту).

Минем яңа кармагым бар. Миңа аны дәү әтием бүләк итте. Якшәмбе иртән мин әти белән балык тотарга киттем. Әтием балыкны кармак белән яхшы тота, ә мин аннан өйрәнәм. Күптән түгел без походта булдык, анда балык тоттык. Балык ашы пешердек. Бик тәмле булды! Ләкин мин балык тота алмадым, балык бик хәйләкәр булып чыкты. Бүген хәйләкәр балыкны тотам! Һичшиксез!

Кич белән без Иделдән шундый зур балык алып кайттык! Беркем дә беркайчан да шундый зур балык күрмәгән! Әниебез шатланды, ләкин шундый зур балыкны чистартырга, пешерергә бик авыр. Без әти белән аңа булыштык.

Без бу балыкны дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе ашадык. Ашадык, ашадык та ардык. Пәнҗешәмбе без күршеләрне чакырдык. Алар да ашадылар, ләкин балыкны ашап бетерә алмадылар. Җомга, шимбә көннәрне барлык туганнарны чакырдык. Алар да безгә балык ашарга булыштылар, ләкин барыбер ярты балык икенче якшәмбегә кадәр калды. Икенче дүшәмбегә генә балыктан бернәрсә дә калмады.

Син Артурга ышанасыңмы? Син ничек уйлыйсың: Артур балык турында дөрес сөйләдеме?

**4. Актуализация знаний.**

Укытучы укучыларның текстны аңлаганнарын тикшерә:

1) укытучы тексттан нәрсә аңлауларын сорый;

2) тексттан туры килгән җөмләләрне табарга тәкъдим итә.

Мәсәлән:

- Якшәмбе иртән нәрсә булды?
- Иделдән нәрсә алып кайттылар?
- Әни нишләде?
- Кем балыкны ашады?

Укучылар кирәкле җөмләләрне табып укыйлар. Кемнең фаразлавы дөрес булып чыкты, шуңа алкышлыйлар.

**5. Физкультминутка.**

Укучылар түгәрәккә басып, алып баручының хәрәкәтләрен эмитация рәвешендә күрсәтәләр. Укучылар да үзләре алып баручы ролендә була алалар.

**6. Обобщение и систематизация знаний.**

Работа в парах: задать к каждому абзацу вопросы. Сосед по парте должен найти в тексте ответ. Затем он задает свой вопрос. На него также нужно ответить. Задать 3 вопроса по одному к каждому абзацу.

**7. Закрепление.** Учитель задает вопросы, учащиеся по цепочке отвечают.

1. Артур атнаның кайсы көне турында язды?
2. Ул ял көне кая җыенды?
3. Ул анда дуслары белән барамы?
4. Әтисе балыкны нәрсә белән тота?

5. Ә Артур балыкны яхшы тотамы?
6. Алар тиз кайттылармы?
7. Алар кайсы елгага бардылар?
8. Алар бик күп балык алып кайттылармы?
9. Әтисе балыкны кая алып керде?
10. Кемнәр әнигә булышты?
11. Балыкны ашап бетерделәрме?
12. Аларга балыкны ашарга кем булышты?
13. Кайчан балыктан бернәрсә дә калмады?
14. Ә син Артурга ышанасыңмы?
15. Бу хәл чыннан да булдымы?

**8. Самостоятельная работа с последующей проверкой.** (Язма эш.)

Учащимся предлагается самостоятельно ответить на вопросы.

1. Бу текст нәрсә турында?
2. Озаглавь текст. Предложи своих 2-3 варианта заглавия. (Предполагаемые ответы: Названия: «Удивительный сон», «Я - рыбак!», «Удачная рыбалка», «Мы с папой супер рыбаки» и др.)
3. Вставь вместо пропусков подходящие по смыслу слова.
   Артурның ___________ бар. Ул әтисе белән ______________ җыена. Күптән түгел ул _________ булды. Ләкин балык ________________. бүген балыкны, һичшиксез, ______________ .
4. Соедини стрелками пары.
   беркем до воскресенья
   бернәрсә никогда
   беркайчан только к понедельнику
   якшәмбегә кадәр ничего
   дүшәмбегә генә никто

5. Прочитай третий абзац текста и напиши, о чём ты задумался после прочтения этого рассказа.
6. Чем закончился рассказ? Ты веришь Артуру или ты думаешь, что он все придумал? Чему научил тебя рассказ? Обоснуй свой ответ.

**9. Включение в систему знаний.**

Что на самом деле могло произойти в то утро воскресного дня? Учитель делит детей на команды (4-5 человек). На листах бумаги А3 дети рисуют/ пишут свой вариант истории за определенный отрезок времени (например, 5-7 минут). Учитель следит за тем, чтобы все члены команды участвовали в работе. На защиту работы приглашаются учащиеся под определенными номерами (например, все члены команды под №3)

Предполагаемый рассказ:

Якшәмбе иртән Артур әтисе белән балык тотарга бара. Аның яңа кармагы бар. Аны аңа дәү әтисе бүләк итте. Ләкин иртән уяныга шундый авыр – Артур йокларга бик ярата. Әтисе аны уятырга тырыша, ләкин Артур шундый каты йоклый. Шуңа күрә әтисе Иделгә балык тотарга үзе генә китә.

Тиздән Артур уяна. Әтисе үзе генә киткән (ушел)! Аның елыйсы килә. Ул бит зур егет! Еларга ярамый! Артур өстәл янына утыра һәм көндәлегенә карый. Иртәгә нинди дәресләр бар?

Кичен Артур белән әнисе әтиләрен көтәләр...

**10. «Мостик» к следующему уроку. Используется структура «Углы».**

Подготовка к проектной работе в командах: Учащимся раздаются цветные эмблемки. Они по цвету находят свой угол и получают задание – подготовить памятку по темам:

Синий угол: «Как быстро и правильно собраться на рыбалку»

Желтый угол: «Советы для начинающего рыбака»

Красный угол: «Рецепт блюда из рыбы»

Зеленый угол: «Когда рыбалка бывает удачной (время года, погода, приметы)»

Образовавшиеся команды обсуждают свою тему и определяют круг вопросов, которые нужно подготовить к следующему уроку: подбор лексики, материала.

– Об этом мы поговорим на следующем уроке. Это тема нашего следующего урока.

**11. Индивидуальная рефлексия.**

– Возьмите каждый по солнышку. В центр солнышка поставьте знак **?** или **!**, с обратной стороны напишите:

– что вызвало затруднения, если поставили **?**

– что вам особенно понравилось и запомнилось на уроке, если выбрали **!**

Все записки складываются в конверт для вопросов для рассмотрения на следующем уроке («Сораулар конверты»)

**12. Домашнее задание.** Выберите дом. задание (на экране компьютера):

Для тех, кто нарисовал знак **?**

- Перескажи понравившуюся часть текста.

Для тех, кто нарисовал знак **!**

- Расскажи о себе (сборы, рыбалка, улов)

– Похвалите друг друга.

Самым активным учащимся раздаются сердечки со словом «Отлично!» («Шәп!»), оно дает право на освобождение от одного домашнего задания.

Укытучы билгеләр куеп чыга, укучылар белән саубуллаша, уңышлар тели.

Развитие функциональной грамотности при работе с текстом

«Шундый зур балык»

| Уровень мышления | Вопросы |
|---|---|
| Знания | Как ходят на рыбалку? Что берут с собой? Чем занимаются в разные дни недели? |
| Понимание | Приведи аргументы, подтверждающие название рассказа «Шундый зур балык». |
| Применение | Расскажи про сборы на рыбалку. Расскажи про интересный случай, который произошел с тобой (с твоими друзьями). Запиши его. |
| Анализ | Проанализируй текст. Выдели дни недели. Что обычно делают в эти дни? |
| Синтез | Составь план рассказа. |
| Оценивание | Опиши, когда ходят на рыбалку, что влияет на улов, какие признаки природы ты бы мог увидеть, оказавшись на рыбалке. |

# ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТЕКСТ ӨСТЕНДӘ ЭШ АЛЫМНАРЫ. КУЛЛАНУ АША ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫГЫН ҮСТЕРҮ

Казан шәһәре, Идел буе районы «52нче гимназия»
МБББУ беренче квалификацион категорияле туган (татар) теле
һәм әдәбияты укытучысы
**Зарипова Эльвира Ильсур кызы**

**Безне адәм иткән — уку, Адәмне алга илткән — уку**

Бүгенге көндә гомуми белем алган укучылар аралашу һәм социаль мөнәсәбәтләрнең киң диапазонын хәл итү өчен кирәкле белем күнекмәләргә ия булырга тиеш. Бу максатка ирешү өчен без балаларда функциональ грамоталылык формалаштырырга тиеш.

- **Функциональ грамоталылык** — кешенең әйләнә-тирә мохит белән мөнәсәбәтләргә керү, гомер дәвамында алынган белемнәрен куллана белү сәләте.
- **Уку грамоталылыгы** — функциональ грамоталылыкның иң мөһим өлеше. Ул — укучыда текстларны аңлау, куллану, бәяләү, алар турында уйлану сәләте үстерә.

Рус төркемнәрендә эшләгәндә уку аеруча зур урын алып тора, чөнки чит тел өйрәнүдә уку төп компонент булып тора. Ул сүз байлыгын киңәйтергә, контексттан таныш булмаган сүләрне аңларга, грамматик категорияләрне ныгытырга, сөйләм күнекмәләрен камилләштерергә булыша.

Уку – коммуникатив-танып белү эшчәнлегенең иң мөһим төрләренең берсе булып фикерләү эшчәнлеге тора. Уку күнекмәләре бик мөһим, чөнки көндәлек тормышта без еш кына язу үрнәкләре белән хәл итәбез: китаплар, матбугат басмалары укыйбыз, интернет челтәрләрендә төрле мәгълүмат эзлибез. Уку кешенең культурасын үстерә, аны шәхес буларак тәрбияли.

«Ничек укытырга?» — «Нәрсә укытырга?» — дип борчылуларыбызга җавап табырга кирәк.

Функциональ грамоталы шәхес үстерү, ягъни белем, күнекмә, осталык ярдәмендә төрле тормыш мәсьәләләрен чишүгә сәләтле һәм зур шәхес тәрбияләүдә әдәбият фәне мөмкинлекләрен куллану укытучының зыялылыгына, актив тормыш позициясенә гомуми компетентлылыгына бәйле булу бәхәссез.

Бүген безгә тәкъдим ителгән татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты белем эчтәлеген заман таләпләренә туры китереп яңарту, аның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү бурычларын хәл итү максатында төзелгән. Ул һәр баланың татар әдәбиятыннан яхшы сыйфатлы белем алуга хокукын гарантияли, һәр укучыга тигез мөмкинлекләр тудыра, гомуми белем бирүнең төрле баскычларындагы укыту программаларының бәйләнешен булдыра, укучыларнын психик һәм физик сәламәтлеген саклый, артык эш күләменнән азат итә, укучыларны һәм укытучыларны социаль яклауны тәэмин итә.

Бүгенге көндә функциональ белемлелек иҗтимагый иминлекнең мөһим индикаторы булып тора, ә укучыларның функциональ грамоталылыгы – белем бирү сыйфатының мөһим күрсәткече.

**Тема: Белем укудан башлана. Мөхәммәдия мәдрәсәсе.**
**Дәреснең максаты:** «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе белән танышу, татар халкының элек-электән белемле булуы турында сөйләшү.
**Бурычлары:**
Белем бирү:
- *укыган текстны аңлап, тарихи күзәтү ясый белү;*
- *тыңлап- аңлау күнекмәләрен камилләштерү;*

Фикер сәләтен үстерү:
- *логик фикерләү сәләтен үстерү;*
- *мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын үстерү;*
- *танып-белүне үстерүгә ярдәм итү;*
- *аралашу күнекмәләрен формалаштыру;*
- *коллективта хезмәттәшлек итү сәләтен үстерү.*

Тәрбияви максат:
- *әңгәмәдәшенә ихтирам тәрбияләү;*
- *балаларда белемгә омтылыш тәрбияләү.*

**Җиһазлау:** презентация, ноутбук, экран, проектор, карточка.
**Дәреснең төре:** яңа белемнәрне үзләштерү дәресе.
**Метод һәм алымнар:** әңгәмә; биремнәрне аерым-аерым үтәү, парлап эшләү.
**Дәрестә кулланган структуралар:** ТЭЙК ОФ–ТАЧ ДАУН.

**Дәрес барышы:**

**I. Оештыру өлеше.**

**1) Исәнләшү.**

- Исәнмесез, укучылар!
- Исәнмесез, Эльвира Ильсуровна!
- Хәерле көн, укучылар!
- Имин үтсен көнегез!
- Кәефләрегез ничек соң?
- Кояшлы иртә кебек,
  Татар телен, Тукай телен
  Өйрәнергә дип килдек.

**2) Фонетик күнегү. 2 нче слайд.**

**[ә] – мә – мә – мәктәп**
**– шә – шә – шәкерт**
**– гә – гә – түгәрәк**
**– чә – чә – кичә**

**I. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.**

1. **Уку мәсьәләсен кую.**

– Ә хәзер экранга карагыз. Биредә сез шакмаклар күрәсез. Безгә әлеге шакмакларны берләштерергә кирәк. Аларны берләштергәч, сүзләр килеп чыга. Ягез, балалар, нинди сүзләр килеп чыга? Шул сүзләр дәресебезнең темасын ачырга ярдәм итәр.

**Уен. «Дөрес парны тап»**

Килеп чыккан сүзләр: мәктәп, белем, дөньясы.

– Шушы сүзләрдән җөмлә төзеп әйтү. **«Мәктәп – белем дөньясы.»** Димәк, без бүген белем алу турында сөйләшүне дәвам итәрбез. Дәрестә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе турында текстны укырбыз, татар халкының элек-электән белемле булуы турында сөйләшербез.

**Ребята, на парте у каждого лежит лист бумаги. Вы в конце урока должны будете сами себя оценить на сколько вы усвоили данную тему.**

**А) Дәрес материалын бик әйбәт үзләштердем, хәтта иптәшләремә дә булыша алам – 5** (материал урока хорошо усвоил, могу рассказать одноклассникам– **5**)

**Б) Әйбәт эшләдем, материалны аңладым – 4**
(на уроке хорошо работал, материал усвоил – **4**)

**В) Әйбәт эшлим, ләкин иптәшемнең ярдәменә каршы килмим – 3** (на уроке хорошо работаю, но от помощи товарища не откажусь – **3**)

**2. Актуальләштерү.**

Ә хәзер алдагы дәрестә алган белемнәрегезне дә тикшереп алырбыз. Мин мәкальләр әйтәм. Минем белән риза булсагыз, басасыз, риза булмасагыз, басмыйсыз.

**Тэйк оф–тач даун.**

- Телләр белгән – илләр белгән. +
- Китап – рәсем папкасы. -
- Беләге көчле берне егар, белеме көчле меңне егар +
- Уку – көрәк белән бәрәңге казу. -

**Нәтиҗә ясау.**

**II. Яңа белемнәрне беренчел үзләштерү.**

Уку мәсьәләсен адымлап чишү этабы.

**Яңа сүзләр белән таныштыру.**

**1. Экранда транскрипция билгеләре белән язылган яңа сүзләр:**

чор [чор] — период
абруйлы [абруйлы] — авторитетный
шәкертләр [шәкэртләр] – ученики медресе, шакирды
әдәби түгәрәкләр [әдәби түгәрәкләр] – литературные кружки
кичәләр [кичәләр] — литературные вечера
кульъязма [къулйазма] — рукопись, здесь; рукописные
1) экранда язылган яңа сүзләрнең мәгънәсен ачыклау (семантизацияләү).
2) Яңа сүзләрнең әйтелеше өстендә эш (укытучы артыннан хор белән һәм аерым-аерым кабатланыла):
- яңа сүздәге үзенчәлекле авазларны әйтү;
- сүзне кабатлау;
- сүзтезмә әйтү: яңа сүз кергән җөмләләр әйтү:

**2. Яңа сүзләр кулланып ситуатив күнегү.**

**Как скажешь о том, что:**

- это авторитетное учебное заведение;
- рукописные газеты-журналы;
- организовывали литературные вечера;
- этот период.

**4. Текст белән танышу.** Әйдәгез, балалар, дәреслекне ачыгыз. 80нче биттә бирелгән текстны укыйбыз. Укытучы укый, 2 укучы укый. («Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең фотосурәтләре).

**Текст өстендә эш.**

**Найдите строчки, где говорится о том, что:**

- медресе «Мухаммадия» открылся в городе Казань в 1882 году;
- это учебное заведение в этот период очень авторитетное;
- что шакирды организовывают литературные кружки и вечера;

- первые рукописные журналы-газеты выпускались шакирдами;
- медресе «Мухаммадия» работает и по сей день.

**III. Яңа белемнәрне үзләштерүне тикшерү.**

**Парларда эш.**

**(Сораулар һәм җаваплар белән карточкалар таратыла. Сорау булган карточкалы укучы дөрес җавап булган карточкалы укучыны эзли)**

1. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе кайда ачыла? («Мөхәммәдия» мәдрәсәсе Казанда ачыла)
2. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе кайчан ачыла? («Мөхәммәдия» мәдрәсәсе 1882 нче елда ачыла)
3. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укучыларны ничек атыйлар? «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укучыларны шәкертләр дип атыйлар)
4. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә нәрсәләр оештыралар? («Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә нәрсәләр оештыралар)
5. Беренче кулъязмаларны кемнәр чыгара? (Беренче кулъязмаларны шәкертләр чыгара)
6. Шәкертләр нәрсәгә омтыла? (Шәкертләр яңалыкка омтыла)
7. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бүген эшлиме? (Әйе, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бүген дә эшли)

**IV. Өй эше.**

**1нче вариант. Укырга һәм тәрҗемә итәргә («3»)**

**2нче вариант. Текст буенча өч сорау уйларга. (81нче бит, 4 сорау) («4»)**

**3нче вариант. Текстның эчтәлеген сөйләргә. («5»)**

**V. Рефлексив бәяләү этабы.**

– Бүгенге дәрестә нәрсә белдегез?

Мин шуны белдем: ...(«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе 1882 нче елда ачыла)

Мин шуны белдем: ...(«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе абруйлы уку йорты була)

Мин шуны белдем: ...(Мәдрәсәдә шәкертләр укый)

Мин шуны белдем: ...(Мәдрәсәдә әдәби түгәрәкләр, кичәләр оештыралар)

Мин шуны белдем: ...(«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бүген дә эшли)

– Ә хәзер мин җөмләләр әйтәм. Минем белән риза булсагыз, елмаю смайлигы күрсәтәсез, риза булмасагыз – киресенчә.

– Без бүген дәрестә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе турында сөйләштек.

– Без бүген дәрестә әкият укыдык.

– Без бүген дәрестә сөйләдек, сорауларга җавап бирдек.

– Дәрестә миңа авыр булды.
– Дәрес миңа ошады.
– Өй эше авыр.

**Йомгаклау.**

1.Укытучының йомгаклау сүзләре.

Кем үзенә «5» ле куйды, өй эшенең 3 нче вариантын сайларга тәкъдим итәм. Кем «4» ле куйды, сезгә 2 нче вариантагы өй эшен, ә кем үзенә «3» ле куйды сезгә 1 нче вариантны эшләргә тәкъдим итәм.

2. Сау булыгыз! Рәхмәт!

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ФУНКЦИОНАЛЬ БЕЛЕМНӘРНЕ БУЛДЫРУГА КҮНЕГҮЛӘР

**Валиева Илсия Яхъя кызы,**
Казан шәһәре Совет районы Абдулла Алиш исемендәге 20нче гимназиянең 1нче квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы

Мәктәпкә һәр бала яхшы укыйм дигән теләк белән килә. Яхшы уку теләге һәр укучының күңелендә була. Укытучылар баланың күңеленә кешелеклелек орлыклары салып, тормышта дөрес юл сайлап, җәмгыятьтә үз урынын табып яшәргә өйрәтүчеләр. Шуңа күрә алар көчле һәм көчсез балалар юклыгын аңлап, барлык балаларны да уку процессы белән кызыксындыру юлларын эзлиләр.

Һәр чорда да укытучылар алдында укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү бурычы торды. Федераль дәүләт белем бирү стандартында укучыларны төрле эшкә җәлеп итү аша, аларның фикерләвен, сөйләмен, рухи үсешен тәэмин итү бурычы билгеләнде. Укучыларга әзер белем бирү белән шөгыльләнмичә, белемне укучыларның үзләреннән таптырту алымнарын күздә тотып укучылар эшчәнлеген оештыру, алган белемнәрен тормышта куллана белергә өйрәтү актуаль проблема әйләнде. Яңа тормыш шартларына яраклашкан, гомуми мәдәни үсешкә ирешкән, үз фикере булган көндәшлеккә сәләтле шәхесләр тәрбияләү белем бирү процессының үзәгендә булды.

Бу бурычларны татар теле дәресләрендә укытучы нинди юллар белән тормышка ашыра ала соң?

Гамәлдә күренгәнчә, укучылар эшчәнлеген оештырганда укытучы һәр дәрестә функциональ грамоталылыкны үстерүгә

зур игътибар бирергә омтыла. Функциональ грамоталы кеше үзенең алган белемнәрен һәм күнекмәләрен тормыш мәсьәләләрен чишүдә, кешеләр белән аралашуда һәм социаль бәйләнешләрдә дөрес итеп куллана белә.

Асылда, без укытучылар, барыбыз да иҗат итәбез. Баланың ак кәгазьдәй саф күңеленә ак нур белән эзләр салабыз. Шул эзләрнең якты, мәгънәле булуы өчен гомеребез буена тырышабыз, эзләнәбез.

Шул максаттан, 2 нче сыйныф өчен татар теленнән күнегүләр җыелмасын тәкъдим итәм.

**1.Хайван атамаларына туры килгән хайван кушаматлары уйлап яз. Өегездә булган хайван атамасы белән җөмлә төзе.**

*Планлаштырылган нәтиҗәләр: хайван кушаматларының баш хәрефтән язылуын ныгыту, балаларның тормышта булган тәҗрибәсен кулланырга этәрү, булган белемнәрне тулыландыру, үз фикереңне төгәл әйтеп бирүне ныгыту.*

Эт, песи, сыер, ат, куян, ташбака, кәҗә.

– **Син үзеңдә нинди хайван булуын теләр идең?**

**2. Табышмакларның җавапларын тап, мәгънәсен аңлат. Җавапларга сорау куй. Сүз төркемен билгелә.**

*Планлаштырылган нәтиҗәләр: сүзнең лексик мәгънәсен дөрес итеп аңлау һәм куллана белү, исем сүз төркемен кергән сүзләрне тану.*

1.Иртә килә, кич кайта. (Кояш)
2.Аяксыз, кулсыз, капка ача. (Җил)
3.Утта янмый, суда батмый. (Боз)
4.Борынсыз чыпчык боз тишә. (Тамчы)
5.Исе юк, төсе юк, аннан башка тормыш юк. (Су)

– **Бу җавапларны бер сүз белән ничек атап була?**

**3. Сүзләрне мәгънәләре буенча тоташтыр. Бер сүзтезмә белән җөмлә төзе.**

*Планлаштырылган нәтиҗәләр*: *сүзләрдән мәгънәләре буенча туры килгән дөрес сүзтезмәләр төзү, сөйләм күнекмәләрен үстерү.*

| | |
|---|---|
| кояш | болытлы |
| куян | батыр |
| көн | куркак |
| егет | якты |

**4. Хайван һәм үсемлек исемнәрен генә күчереп яз. Бер хайван яки үсемлек турында сөйлә.**

*Планлаштырылган нәтиҗәләр*: *сүзләрне дөрес итеп төркемнәргә бүлү, үз фикереңне башкаларга дөрес итеп җиткерә белү*.

Бүре, кычыткан, кояш, аю, әрекмән, сыер, кузгалак, кеше, песи, эт, чәчәк, агач.

**5.Бирелгән җөмләне сорау, тыныч тавыш һәм гаҗәпләнүне күрсәткән интонация белән укы.**

*Планлаштырылган нәтиҗәләр*: *дөрес интонация белән җөмләләрне уку, сөйләм күнекмәләрен үстерү*.

Син яхшы йөзә беләсең?

Син яхшы йөзә беләсең.

Син яхшы йөзә беләсең!

- **Бер җөмлә төзе һәм төрле интонация белән укы.**

**6.Бирелгән сүзләрдән иптәшең белән диалог төзе. Сөйләп күрсәт.**

*Планлаштырылган нәтиҗәләр: дөрес итеп аралашу күнекмәләрен үстерү, сөйләм байлыгын арттыру*.

Исәнме, кая, сатып алам, кибет, алма, сау бул, син, дустым, барасың, ә, нәрсә, китапханә, аласың, китап.

**7. Иптәшең белән киңәшләшеп хаталарны тап, күчереп яз.**

*Планлаштырылган нәтиҗәләр: дөрес язу һәм бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү*.

Янгыр, мектеп, орлок, хава, айу, урдәк, жәй, ямле.

- **Бер сүз белән җөмлә төзе.**

**8. Төшеп калган хәрефләрне куй, сүзләрнең язылышын орфографик сүзлек кулланып тикшер, күчереп яз.**

*Планлаштырылган нәтиҗәләр: дөрес язу һәм сүзлек белән эшләү күнекмәләрен үстерү*.

Ав-л, б-р-ңге, я-рак,б-тергеч, к-тап, к-ләм, дәре-лек, к-рандаш.

- **Уку әсбапларын ата.**

**9. Сыйныф бүлмәсендә булган 10 предмет исемен ата. Бу предметларның берничә билгесен әйт. Бер җөмлә төзе.**

*Планлаштырылган нәтиҗәләр: сүзләрне дөрес итеп атау, сүзтезмәләр төзү.*

**10. Үрнәк буенча дустыңа яки туганыңа хат яз.**
**Планлаштырылган нәтиҗәләр: хат язу үрнәге белән таныштыру, бәйләнешле сөйләм күнекмәсен үстерү.**

Исәнме, дустым Азат!

Бу хатны сина дустың Марат яза. Хәлләрең ничек?
Мин үзем укып йөрим. Футбол түгәрәгенә йөрим. Миңа бик ошый.
Каникулларда Казанга киләсеңме? Бергәләп кино карарбыз, футбол уйнарбыз, паркларга йөрербез.

Дустың Марат.

ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ
БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ
ГРАМОТАЛЫЛЫКЛАРЫН
ФОРМАЛАШТЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Методик тәкъдимнәр
Форм.бум.60х84 1/16. Усл.п.л.2,8
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ
420015 Казан, Зур Кызыл ур., 68
Тел.: (843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42 E-mail: irort2011@gmail.com

# Уважаемые коллеги,
# приглашаем к сотрудничеству!

## СОВРЕМЕННОЕ ОБРАЗОВАНИЕ: АКТУАЛЬНЫЕ ВОПРОСЫ И ИННОВАЦИИ

**Свидетельство о регистрации СМИ: ЭЛ № ФС 77-74813**

*(выдано Федеральной службой по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций)*




**Территория распространения:**
Российская Федерация и зарубежные страны
**Периодичность:** четыре раза в год
Опубликованные материалы будут размещены в Научной электронной библиотеке (e-library.ru) и войдут в базу данных **Российского индекса научного цитирования (РИНЦ)**
**Контактное лицо:** Шайхутдинова Галия Айратовна
**Адрес электронной почты:** smi@irort.ru

**Подробная информация для авторов** http://irortsmi.ru/node/3

## АКТУАЛЬНАЯ ПЕДАГОГИКА




**Территория распространения:**
Российская Федерация и зарубежные страны
**Свидетельство о регистрации:** ПИ №ФС77-75641 от 26 апреля 2019 г.
Материалы публикуются **на русском и татарском языках**
**Контактное лицо:** Абдулаев Валерий Анатольевич
**Номер телефона редакции:** 8 937610 37 60
**Адрес электронной почты:** vabdulaev@inbox.ru







Институт развития образования
Республики Татарстан
420015, Казань, Большая Красная, 68
(843) 236-65-63, 236-62-42
irort2011@gmail.com